# *Белемең белән сөендер.

(4 нче сыйныфта татар теленнән дәрес- зачет)





* **Дәреснең девизы:**

“Тел дигән дәрья бар,
Төбендә энҗе- мәрҗән
бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры
калыр.”

* **Җылы төстәге хәрефләрне сайлап дәреснең исемен укыгыз.**
* А с и ү к ң з ч т у ө ф р м п к л е о м ы н ш ә й р х е

# Тема. Сүз төркемнәрен ныгыту.

## Максат.

1.Исем, сыйфат, фигыль сүз төркемнәре турындагы белемнәрен ныгыту;

2.Укучыларның үз фикерләрен әйтә, дәлилли, шулардан нәтиҗә ясый белүләренә ирешү,

3.Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен, фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эшне дәвам итү;

4.Укуга җитди караш, игътибарлылык, пөхтәлек тәрбияләү.

* Сүзләрне грамматик мәгънәләренә карап төркемлик.

1. Әни, Гали, сандугач, сыерчык, төлке, аю, давыл, йокы, Кукмара.
2. Ак , кара, татлы, әче, җиңел, авыр, кыю, куркак, юан, нәзек.
3. Ура, себерә, юа,оча, йөгерә, бөгелә, йоклый, җырлый, шатлана.
4. Мин, без, син, ул, сез, алар, миңа, синңа, безгә.

# Сүзлек эше:

**г..илә, д..нә, дөн..я, җи..аз, к..дерле, күңе....е, ашх..нә, г.. дәт, дәв..м, зин..ар, и..тирам, иг..тибар, тәм..м.**

* Сүзлек эше:

**гаилә, данә, дөнья, җиһаз, кадерле, күңелле, ашханә, гадәт, дәвам, зинһар, ихтирам, игътибар, тәмам.**

* Исем сүз төркеме турындагы белемнәребезне барлыйк:

-нәрсә ул исем?

-нинди исемнәр бар?

-нинди исемнәр уртаклык исемнәр дип атала?

-нинди исемнәр ялгызлык исемнәр дип атала?

-исемгә мисаллар китерегез.

-исем нинди сорауларга җавап бирә?

-исемнәр нәрсәләр белән төрләнә?

-исемнәр нинди җөмлә кисәге булып килә?

* Сүз башындагы тартыкларны алыштырып, яңа сүз ясарга.

- җиләк –
- күлмәк -
- бала -
- көймә -
- шүре –
- кире –
- баш –
- тау -

- чиләк
- чүлмәк
- кала
- төймә
- бүре
- тире
- таш
- бау

# *Сүз уртасындагы тартыкларны алыштырып, яңа сүзләр ясарга.

- терәк –
- идән –
- карчык –
- тармак –
- үрдәк –
- күпер –
- илле –
- иләк –
- кашык -
- кабак –
- ишек –
- кырык -

- теләк
- имән
- капчык
- такмак
- үрнәк
- күмер
- ипле
- итәк
- катык
- кадак
- итек
- кызык

* Урам, арпа,таш сүзләрен килешләр белән төрләндереп язарга.